# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында" һәм "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 29 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче "Октябрь авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территорияләре чикләрен һәм "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш жирдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче "Октябрь авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**


"Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында" 2004 елның 15 сентябрендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 8 – 9; 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (VI өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда "Муниципаль берәмлек буларак" сүзләреннән соң "Казан шәһәреннән һәм аның янәшәсендәге территорияләрдән торучы" сүзләрен өстәргә;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

# Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре **карта схемасы**




Шартлы билгеләр

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге

41 - тоташу ноктасының тәртил саны

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чиктәш чикләре тасвирламасы

*43-44* - Биектау муниципаль районы
*44-45* - Питрәч муниципаль районы
*45-41* - Лаеш муниципаль районы
*41-40* - Югары Ослан муниципаль районы
*40-43* - Зеленодольск муниципаль районы";

3) 2 нче кушымтаның өченче – тугызынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Югары Ослан һәм Зеленодольск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=475381,48, Y=1287907,55 координаталы 40 нчы тоташу ноктасыннан төньякка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 510 м Казан – Түбән Новгород автоюлы үзәгеннән 100 м сусаклагычның яр буе линиясенә кадәр уза, аннары 465 м шул ук юнәлештә Казан – Түбән Новгород автоюлы үзәгеннән 85 м уза, көнбатышка 15 м, аннары төньякка 2810 м яңадан Казан – Түбән Новгород автоюлы үзәгеннән 100 м уза;

алга таба чик 100 м төньяк-көнбатышка, аннары шул ук юнәлештә 1590 м сынык сызык белән Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 80 м аның яр буе линиясеннән көньяккарак уза;

алга таба чик 80 м төньякка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча сусаклагычның яр буе линиясенә кадәр һәм аннары 120 м Казан – Зеленодольск тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чигенә кадәр уза;

алга таба чик 90 м төньяк-көнбатышка Казан – Зеленодольск тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза;

аннары чик 1630 м көнчыгышка таба Казан – Зеленодольск тимер юлы полосасының көньяк чигенә кадәр уза, аннары 50 м төньяк-көнчыгышка һәм 20 м көнчыгышка Зеленодольск тәҗрибә-үрнәк урман хуҗалыгының Васильево урманчылыгындагы 179 нчы кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза;

алга таба чик 1320 м төньяк-көнчыгышка Казан – Түбән Новгород автоюлы күчәреннән 25 м, 30 м төньяк-көнбатышка, 85 м төньякка, 25 м төньяк-көнчыгышка сәнәгать объекты чикләре буенча уза, аннары 1680 м төньякка һәм 25 м Казан – Түбән Новгород автоюлы күчәреннән алып Казан – Түбән Новгород автоюлы транспорт киселеше табанында урнашкан ноктага кадәр дәвам итә;

алга таба чик 660 м төньяк-көнбатышка Казан – Түбән Новгород автоюлының транспорт киселешенең көньяк-көнбатыш өлешендәге табан буенча уза, аннары 50 м төньякка Казан – Түбән Новгород автоюлын кисеп уза, аннары 285 м төньяк-көнбатышка Казан – Түбән Новгород автоюлы транспорт киселешенең төньяк-көнбатыш өлешендәге табан буенча чокыр белән киселешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр дәвам итә;";

4) унынчы – ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**3 статья**

"Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 12 (I өлеш), 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре <u>карта-схемасы</u>




**Шартлы билгеләр**

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- <u>10</u> - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

**Муниципаль районның читтәш чикләре тасвирламасы**

| | |
|---|---|
| *41 (9) - 4 (10)* | Чуваш Республикасы, Марий Эл Республикасы |
| *4 (10) - 9 (43)* | Биектау муниципаль районы |
| *9 (43) - 11 (40)* | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| *11 (10) - 31 (39)* | Югары Ослан муниципаль районы |
| *34 (39) - 41 (9)* | Кайбыч муниципаль районы |

"Зеленодольск муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Зеленодольск шәһәре |
| 2 | Васильево шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы |
| 4 | Әйшә авыл җирлеге |
| 5 | Акъегет авыл җирлеге |
| 6 | Бишнә авыл җирлеге |
| 7 | Олы Ачасыр авыл җирлеге |
| 8 | Большие Ключи авыл җирлеге |
| 9 | Олы Карагуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Олы Ходяш авыл җирлеге |
| 11 | Олы Шырдан авыл җирлеге |
| 12 | Олы Җәке авыл җирлеге |
| 13 | Күгәй авыл җирлеге |
| 14 | Күгеш авыл җирлеге |
| 15 | Мамадыш-Әкил авыл җирлеге |
| 16 | Мизиново авыл җирлеге |
| 17 | Мулла Иле авыл җирлеге |
| 18 | Түбән Урысбага авыл җирлеге |
| 19 | Новопольский авыл җирлеге |
| 20 | Норлат авыл җирлеге |
| 21 | Октябрь авыл җирлеге |
| 22 | Осиново авыл җирлеге |
| 23 | Раифа авыл җирлеге |
| 24 | Рус Әҗиле авыл җирлеге |
| 25 | Свияжск (Зөя) авыл җирлеге |
| 26 | Өтәшкә авыл җирлеге". |

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2012 елның 13 гыйнвары
№ 10-ТРЗ

# Әлеге Закон нигезендә чикләре үзгәрүче муниципаль берәмлекләр территорияләренең **карта-схемасы**

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында" һәм "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына кушымта




Шартлы билгеләр

- муниципаль берәмлекләрнең чикләре

- торак пунктлары

- А-Б - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы, аның составына керүче Октябрь авыл җирлегенең чиктәш чиге үзгәрүләрен исәпкә алып

I - Зеленодольск муниципаль районы һәм аның составына кертелүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе

II - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Зеленодольск муниципаль районы һәм аның составындагы Октябрь авыл җирлеге территориясе